**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы турында**

Татарстан Республикасында студентлар отрядларының хезмәт эшчәнлеге абруен күтәрү һәм аларны бүләкләү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ел саен «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» республика конкурсын уздыру һәм җиңүчене Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы белән бүләкләү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» республика конкурсы җиңүчесен бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелын гамәлгә куярга.

3. Түбәндәгеләрне расларга:
Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы турында нигезләмәне (1 нче кушымта);
Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы тасвирламасын (2 нче кушымта);
Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы рәсемен (3 нче кушымта);
Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы белән бүләкләү турында таныклык тасвирламасын (4 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:
«Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» республика конкурсын ел саен уздыруны;

«Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» республика конкурсын уздыру турында нигезләмәне раслауны;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелын һәм аның белән бүләкләү турында таныклыкны эшләүне;

әлеге Указны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 02 сентябрь
№ 711

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның « 02 » сентябрендәге
711 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы (алга таба – Вымпел) Татарстан Республикасы Рәисенең студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтен үстерүгә, аларның Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертүенә этәргеч бирүгә, шулай ук аларның хезмәт, проект һәм иҗтимагый эшчәнлектәге уңышларын стимуллаштыруга юнәлтелгән бүләкләү рәвеше булып тора.

2. Вымпел белән Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» республика конкурсы (алга таба – Конкурс) җиңүчесе булган студентлар хезмәт отряды бүләкләнә. Вымпел Татарстан Республикасы Рәисе яки аның йөкләмәсе буенча башка вәкаләтле зат тарафыннан тантаналы шартларда тапшырыла.

3. Вымпелны Конкурста җиңеп чыккан студентлар хезмәт отрядына тапшыру моментыннан алып, аны саклау һәм тиешенчә файдалану өчен әлеге студентлар хезмәт отряды командиры җаваплы була.

4. Вымпел Конкурста җиңеп чыккан студентлар отряды эшчәнлек алып барган мәгариф оешмасында һәркемгә күренерлек урында куела.

5. Конкурста җиңеп чыккан студентлар отряды Вымпелны студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтенең максатлары һәм бурычларына туры килә торган тантаналы чараларда куллана.

Вымпел белән эш иткәндә аның рәвешен үзгәртү тыела, аңа чит билгеләр урнаштыру, шулай ук аны коммерция максатларында куллану рөхсәт ителми.

Бу пунктның беренче абзацында күрсәтелмәгән очракларда, Вымпел Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән килештереп кулланыла.

6. Чираттагы Конкурста катнашуга заявкалар кабул ителә башлау белән Вымпел Министрлыкка кайтарылырга тиеш.

Вымпелны чираттагы Конкурста җиңеп чыккан студентлар хезмәт отрядына тапшырганчы һәм аны узган елгы Конкурста җиңгән отряд кайтарганнан соң саклауны Министрлык тәэмин итә.

7. Конкурста җиңеп чыккан студентлар хезмәт отряды эшчәнлеген туктаткан очракта, Вымпел бу студентлар хезмәт отрядының эшчәнлеген туктатуы турында карар кабул ителгән көннән 10 эш көне эчендә Министрлыкка кайтарылырга тиеш.

8. Конкурста җиңеп чыккан студентлар хезмәт отряды тарафыннан Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын яисә әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган Вымпелны куллану турындагы нигезләмәләрне үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, Министрлык Вымпелны вакытыннан алда кайтару эшен башларга хокуклы.

9. Вымпел югалган яки аңа зыян китерелгән очракта, Конкурста җиңеп чыккан студентлар хезмәт отряды аның исеменнән эш йөртүче командиры аша Министрлык белән үзара хезмәттәшлектә аны торгызуны тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «02» сентябрендәге
711 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы**
**ТАСВИРЛАМАСЫ**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы (алга таба – Вымпел) тукымадан, саптан, очлыктан, беркеткечтән һәм аслыктан гыйбарәт.

2. Вымпел өслеге ике катлап бөкләнгән, квадрат формасындагы, кызыл төстәге тукымадан эшләнгән. Тукымага өч яктан алтынсу төстәге чук тегелгән, тукыма кырые алтынсу төстәге тасма белән каймаланган. Чукны санамыйча, тукыманың буе һәм иңе – 90 см.

Тукыманың алгы ягында уртада Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән, аның өстендә «ВЫМПЕЛ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» сүзләре (ике юлда), ә астында – «ЛУЧШИЙ СТУДЕНЧЕСКИЙ ТРУДОВОЙ ОТРЯД В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН» (өч юлда) сүзләре чигеп язылган.

Тукыманың икенче ягында уртада Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән, аның өстендә «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ ВЫМПЕЛЫ» сүзләре (ике юлда), ә астында – «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА СТУДЕНТЛАРНЫҢ ИҢ ЯХШЫ ХЕЗМӘТ ОТРЯДЫ» (өч юлда) сүзләре чигеп язылган.

Татарстан Республикасының Дәүләт гербы һәм тукымадагы барлык язулар алтынсу төстәге җепләр белән машина белән чигү ысулында башкарылган.

3. Вымпел сабы агачтан, аркылы кисемендә – түгәрәк, диаметры 4 см, озынлыгы 250 см, караңгы кызгылт-көрән төскә буялган һәм лакланган. Очлыгы агачтан, сөңге очы рәвешендә, лакланган, караңгы кызгылт-көрән төскә буялган. Беркеткече 9 см озынлыктагы кисек конус рәвешендә. Аслыгы агачтан, түгәрәк формада, яссы нигезле, караңгы кызгылт-көрән төскә буялган һәм лакланган.

4. Вымпел тукымасы сапка очлыкның аскы кырыена алтынсу үрелгән ефәк бау ярдәмендә эленгән очлары сөңге очы рәвешендәге агач таякка беркетелгән. Бауның алтынсу икешәр чуклы ике очы Вымпелның өске ике яныннан 70 см озынлыкта эленеп тора.

---

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның « 02 » сентябрендәге
711 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы**
**РӘСЕМЕ**

Алгы ягы



Икенче ягы


ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ ВЫМПЕЛЫ
ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
СТУДЕНТЛАРНЫҢ ИҢ ЯХШЫ
ХЕЗМӘТ ОТРЯДЫ

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «02» сентябрендәге
711 номерлы Указына
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы белән бүләкләү турында таныклык**
**ТАСВИРЛАМАСЫ**

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы белән бүләкләү турында таныклык (алга таба – таныклык) горизонталь урнашкан 300 х 400 мм үлчәмдәге агартылган ялтыравыксыз кәгазь битеннән гыйбарәт.

Битнең алгы ягы бит читеннән 5 мм эчтәрәк, периметры буенча 37 мм киңлектәге кыса эченә урнаштырылган, офсет басма белән башкарылган бизәк белән каймаланган.

Таныклык тексты саклагыч тангир челтәр фонында һәм бит читеннән 42 мм эчтәрәк ясалган караңгы яшел төстәге кысага урнаштырылган.

Өске өлештә уртада битнең өске читеннән 52 мм эчтәрәк 26 мм диаметрлы, офсет басма белән башкарылган Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте урнаштырылган.

Өске якта Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан сулда һәм уңда бер юлда, офсет басма белән башкарылган 4 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән тиешле тәртиптә «РАИС РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» һәм «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ» сүзләре урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербының сул ягында астарак «РАИС РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» юлыннан 20 мм ара калдырып, офсет басма белән башкарылган 5 мм (баш) һәм 3,5 мм (юл) зурлыктагы хәрефләр белән «СВИДЕТЕЛЬСТВО о награждении переходящим вымпелом Раиса Республики Татарстан «ЛУЧШИЙ СТУДЕНЧЕСКИЙ ТРУДОВОЙ ОТРЯД В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН» сүзләре урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербының уң ягында астарак «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ» юлыннан 20 мм ара калдырып офсет басма белән башкарылган 5 мм (баш) һәм 3,5 мм (юл) зурлыктагы хәрефләр белән «Татарстан Республикасы Рәисенең «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА СТУДЕНТЛАРНЫҢ ИҢ ЯХШЫ ХЕЗМӘТ ОТРЯДЫ» күчмә вымпелы белән бүләкләү турында ТАНЫКЛЫК» сүзләре урнаштырылган.

Битнең сул ягында «СВИДЕТЕЛЬСТВО о награждении переходящим вымпелом Раиса Республики Татарстан «ЛУЧШИЙ СТУДЕНЧЕСКИЙ ТРУДОВОЙ ОТРЯД В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН» сүзләреннән астарак 15 мм ара калдырып караңгы куе кызыл төстәге 4 мм (баш) һәм 3 мм (юл)

зурлыктагы хәрефләр белән түбәндәге текст басыла:

«Указом Раиса Республики Татарстан от «___» ________ 20___ года № ___

_____________________________________________________________________

(наименование студенческого трудового отряда)

награждается переходящим вымпелом Раиса Республики Татарстан «Лучший студенческий трудовой отряд в Республике Татарстан».

Битнең уң ягында «Татарстан Республикасы Рәисенең «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА СТУДЕНТЛАРНЫҢ ИҢ ЯХШЫ ХЕЗМӘТ ОТРЯДЫ» күчмә вымпелы белән бүләкләү турында ТАНЫКЛЫК» сүзләреннән астарак 15 мм калдырып караңгы куе кызыл төстәге 4 мм (баш) һәм 3 мм (юл) зурлыктагы хәрефләр белән түбәндәге текст басыла:

«Татарстан Республикасы Рәисенең 20____ елның «____» _______ ___ номерлы Указы нигезендә

_____________________________________________________

(студентлар хезмәт отряды атамасы)

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында студентларның иң яхшы хезмәт отряды» күчмә вымпелы белән бүләкләнә».

Текст астында 15 мм ара калдырып уртада Татарстан Республикасы Рәисе имзасы һәм имзаның шәрехе урнаштырылган, ул сулда рус телендә, уңда татар телендә караңгы куе кызыл төстәге 4 мм зурлыктагы баш хәрефләр белән басылган Татарстан Республикасы Рәисенең исеменең баш хәрефеннән, әтисе исеменең баш хәрефеннән һәм фамилиясеннән гыйбарәт.

Аскы өлештә уртада караңгы куе кызыл төстәге 4 мм (баш) һәм 3 мм (юл) зурлыктагы хәрефләр белән басылган «Казань, 20__ год» сүзләре урнаштырылган.

__________